**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 16 декабрь № 940

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 28 декабрь, 1078 нче, 2014 ел, 22 февраль, 109 нчы, 2014 ел, 24 февраль, 118 нче, 2014 ел, 30 апрель, 284 нче, 2014 ел, 2 июнь, 374 нче, 2014 ел, 17 июнь, 418 нче, 2014 ел, 8 июль, 473 нче, 2014 ел, 9 июль, 477 нче, 2014 ел, 25 август, 612 нче, 2014 ел, 1 октябрь, 709 нчы, 2014 ел, 24 ноябрь, 901 нче, 2014 ел, 06 декабрь, 956 нчы, 2014 ел, 31 декабрь, 1083 нче, 2015 ел. 1 июнь, 390 нчы, 2015 ел, 24 июнь, 459 нчы, 2015 ел, 25 июнь, 460 нчы, 2015 ел, 28 июль, 549 нчы, 2015 ел, 16 октябрь, 770 нче, 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы, 2015 ел, 28 декабрь, 992 нче; 2016 ел, 31 март, 190 нчы; 2016 ел, 30 апрель, 268 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Ярдәмче программалар исемлеге» юлында:

2 һәм 3 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. 2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү;

3. 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү;»;

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. 2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү;»;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | «Программаны финанслауның гомуми күләме 14 567 855,04492 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 9 537 443,26762 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 4 287 027,9073 мең сум, җирле бюджетлар акчасы исәбеннән – 3 625,0 мең сум һәм бюджеттан тыш чыганаклардан – 739 758,87 мең сум: |

| Ел | Акча күләме, мең сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | барысы | шул исәптән | | | |
| | | Татарстан Республикасы бюджетыннан | җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча | | |
| | | | федераль бюджеттан | җирле бюджеттан | бюджеттан тыш чыганаклардан |
| 2014 | 3 669 180,11820 | 1 794 954,54562 | 1 717 775,57258 <**> | 100,0 | 156 350,0 |
| 2015 | 3 807 789,58009 | 1 908 009,59 | 1 701 821,12009 <***> | 150,0 | 197 808,87 |
| 2016 | 2 410 557,71463 | 1 640 196,0 | 596 181,71463 <****> | 300,0 | 173 900,0 |
| 2017 | 1 706 063,652 | 1 518 135,152 | 135 743,5 <*> | 760,0 | 51 425,0 |
| 2018 | 1 214 268,86 | 1 025 572,86 | 135 506,0 <*> | 765,0 | 52 425,0 |
| 2019 | 879 482,56 | 825 287,56 | <*> | 770,0 | 53 425,0 |
| 2020 | 880 492,56 | 825 287,56 | <*> | 780,0 | 54 425,0 |
| **Барлыгы** | **14 567 855,04492** | **9 537 443,26762** | **4 287 027,9073** | **3 625,0** | **739 758,87** |

Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

<*> Федераль бюджет акчасы исәбеннән Программаны ресурслар белән тәэмин итү күләме бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларын конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча ел саен билгеләнә.

<**> Шул исәптән 193 209,83529 мең сум – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 декабрь, 1151 нче карары белән расланган 2011 – 2013 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча республика программасы чараларын тормышка ашыруга 2012 – 2013 елларда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган һәм 2014 елда үзләштерелгән акчасы.

<***> Шул исәптән 437 206,63906 мең сум – «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыруга 2014 елда

| | |
|---|---|
| | алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган һәм 2015 елда үзләштерелгән акчасы.<br><****> Шул исәптән 1 364,34855 мең сум – «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыруга 2015 елда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган һәм 2016 елда үзләштерергә планлаштырыла торган акчасы»; |

«Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлының егерме икенче һәм егерме өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ярдәм күрсәтелгән социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар саны 122 берәмлеккә кадәр артуга;

2020 елга Татарстан Республикасы территориясендә территориаль иҗтимагый үзидарәләр саны 373 берәмлеккә кадәр артуга;»;

Программаның II бүлегендәге уникенче һәм унөченче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү»;

3) «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү»;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 14 567 855,04492 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 9 537 443,26762 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 4 287 027,9073 мең сум, җирле бюджетлар акчасы исәбеннән – 3 625,0 мең сум һәм бюджеттан тыш чыганаклардан – 739 758,87 мең сум:

| Ел | Акча күләме, мең сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | барысы | шул исәптән | | | |
| | | Татарстан Республикасы бюджетыннан | җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча | | |
| | | | федераль бюджеттан | җирле бюджет-тан | бюджеттан тыш чыганаклардан |
| 2014 | 3 669 180,11820 | 1 794 954,54562 | 1 717 775,57258 <**> | 100,0 | 156 350,00 |
| 2015 | 3 807 789,58009 | 1 908 009,59 | 1 701 821,12009 <***> | 150,0 | 197 808,87 |
| 2016 | 2 410 557,71463 | 1 640 196,0 | 596 181,71463 <****> | 300,0 | 173 900,00 |
| 2017 | 1 706 063,652 | 1 518 135,152 | 135 743,5 <*> | 760,0 | 51 425,00 |
| 2018 | 1 214 268,86 | 1 025 572,86 | 135 506,0 <*> | 765,0 | 52 425,00 |
| 2019 | 879 482,56 | 825 287,56 | <*> | 770,0 | 53 425,00 |
| 2020 | 880 492,56 | 825 287,56 | <*> | 780,0 | 54 425,00 |
| Барлыгы | 14 567 855,04492 | 9 537 443,26762 | 4 287 027,9073 | 3 625,0 | 739 758,87 |

Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

<*> Федераль бюджет акчасы исәбеннән Программаны ресурслар белән тәэмин итү күләме бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларын конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча ел саен билгеләнә.

<**> Шул исәптән 193 209,83529 мең сум – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 декабрь, 1151 нче карары белән расланган 2011 – 2013 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча республика программасы чараларын тормышка ашыруга 2012 – 2013 елларда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган һәм 2014 елда үзләштерелгән акчасы.

<***> Шул исәптән 437 206,63906 мең сум – «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыруга 2014 елда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган һәм 2015 елда үзләштерелгән акчасы.

<****> Шул исәптән 1 364,34855 мең сум – «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыруга 2015 елда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган һәм 2016 елда үзләштерергә планлаштырыла торган акчасы»;

Программага 1 нче кушымтада:

«Эш белән тәэмин ителгән халыкның гомуми санында микропредприятиеләрдә, кече һәм урта предприятиеләрдә һәм шәхси эшмәкәрләрдә эш белән тәэмин ителгән хезмәткәрләрнең уртача исемлек (тышкы ике урында эшләүдән тыш) саны өлеше, процент» юлында 6 графада «27» саннарын – «26» саннарына, 8 графада «-» билгесен «25» саннарына алмаштырырга;

«Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны (шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп) 1 мең кешегә исәпләгәндә, берәмлек» юлында 6 графада «37» саннарын – «36» саннарына, 8 графада «-» билгесен «35» саннарына алмаштырырга;

«Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген стимуллаштыру» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген стимуллаштыру | Ярдәм күрсәтелгән социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар саны, берәмлек | ки-мен дә 120 | ки-мен дә 140 | ки-мен дә 163 | кимен-дә 90 <*> | кимендә 96 <*> | кимен-дә 104 <*> | кимендә 112 <*> | кимендә 122 <*>»; |

«Татарстан Республикасы территориясендә территориаль иҗтимагый үзидарәләр (алга таба – ТИҮ) саны, берәмлек» һәм «Татарстан Республикасы халкының гомуми санынnan территориаль иҗтимагый үзидарәләргә берләшкән халык өлеше, процент» юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасы территориясендә террито- | 116 | 297 | 338 | 347 | 358 | 363 | 368 | 373 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| риаль иҗтимагый үзидарәләр (алга таба – ТИҮ) саны, берәмлек | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы халкының гомуми саныннан территориаль иҗтимагый үзидарәләргә берләшкән халык өлеше, процент | 19 | 25 | 35 | 36 | 37 | 38 | 38 | 38»; |

түбәндәге эчтәлекле астөшермә өстәргә:

«<*> Федераль бюджет акчасы исәбеннән ярдәм күрсәтеләчәк социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар саны «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү» ярдәмче программасын тормышка ашыру кысаларында социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтүнең төбәк программаларын гамәлгә ашыруга бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларын конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча ел саен билгеләнә.»;

Программага 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасында (алга таба – 1 нче ярдәмче программа):

1 нче ярдәмче программа паспортының «Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлында:

утыз алтынчы – утыз сигезенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2020 елга Татарстан Республикасы территориясендә территориаль иҗтимагый үзидарәләр 373 берәмлеккә җитәчәк;

2020 елга Татарстан Республикасы халкының гомуми саныннан территориаль иҗтимагый үзидарәләргә берләшкән халык өлеше 38 процентка җитәчәк;

территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең гомуми саныннан иҗтимагый үзидарәләр җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтелә торган территориаль иҗтимагый үзидарәләр өлеше ел саен 100 процент тәшкил итәчәк;»;

утыз сигезенче абзацны төшереп калдырырга;

1 нче ярдәмче программаның I бүлегендәге «Халыкны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җәлеп итү һәм халыкның Татарстан Республикасының иҗтимагый-сәяси тормышында катнашу активлыгын арттыру» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халыкны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җәлеп итү һәм халыкның Татарстан Республикасының иҗтимагый-сәяси тормышында катнашу активлыгын арттыру

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, ФЗ-131 нче Федераль закон нигезендә (алга таба – ФЗ-131 нче Федераль закон) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары административ хакимиятнең тигез хокуклы партнерлары сыйфатында карала башлады.

ФЗ-131 нче Федераль законның 33 статьясындагы 2 нче пунктта җирле үзидарә органнары халыкка җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда булышлык күрсәтергә тиеш дип билгеләнгән.

Территориаль иҗтимагый үзидарә (алга таба – ТИҮ) – җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне мөстәкыйль рәвештә хәл итү өчен гражданнарның яшәү урыны буенча үзоешуы, аларның төп эшчәнлек максаты булып мөһим проблемаларны хәл итү генә түгел, гражданнарның яшәү сыйфатын күтәрү, үсеш алган гражданнар җәмгыяте төзү тора. ТИҮ оешмалары бер үк вакытта ачык хакимият структуралары да, коммерциячел булмаган хуҗалык итүче субъектлар да булып тора. Гражданнарны җирле үзидарәдә катнашуга җәлеп итү бурычларын хәл итүдә алар иң мөһим роль уйный.

ФЗ-131 нче Федераль законның 27 статьясы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 ел, 28 июль, ТРЗ-45 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә хәзерге вакытта Татарстан Республикасының муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында гражданнарның яшәү урыны буенча иҗтимагый формированиеләр – ТИҮ төзелә.

2016 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасының муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында 347 ТИҮ төзелгән һәм эшчәнлекләрен гамәлгә ашыра (51 – Казан шәһәрендә, 65 – Чаллы шәһәрендә, 4 – Әгерҗе, 17 – Азнакай, 5 – Аксубай, 36 – Әлмәт, 5 – Арча, 4 – Баулы, 5 – Бөгелмә, 6 – Буа, 10 – Алабуга, 6 – Зәй, 8 – Зеленодольск, 20 – Кама Тамагы, 4 – Кукмара, 7 – Лаеш, 13 – Лениногорск, 15 – Мамадыш, 5 – Менделеевск, 5 – Минзәлә, 1 – Яңа Чишмә, 28 – Түбән Кама, 13 – Нурлат, 1 – Спас, 5 – Тәтеш, 8 – Чистай муниципаль районнарында), шулардан 37 ТИҮ юридик зат статусына ия (13 – Лениногорск, 8 – Зеленодольск, 5 – Арча, 3 – Баулы, 3 – Азнакай, 1 – Яңа Чишмә муниципаль районнарында, 2 – Чаллы шәһәрендә һәм 2 – Казан шәһәрендә).

| ТИҮ гомуми саны, берәмлек | | Юридик зат буларак теркәлгән ТИҮ гомуми саны, берәмлек | | ТИҮ чикләрендә яшәүчеләрнең гомуми саны, мең кеше |
|---|---|---|---|---|
| 2012 ел | 2016 ел (ел башына) | 2012 ел | 2016 ел (ел башына) | 2016 ел |
| 96 | 347 | 12 | 37 | 1 390,3 |

Хәзерге вакытта ТИҮ халыкның 36 процентын яки 1,39 млн.кешене җәлеп итә.

ТИҮне үстерү максатларында, Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориаль

иҗтимагый үзидарәләренең социаль проектлары конкурсын үткәрү турында» (алга таба – Конкурс) 2014 ел, 15 декабрь, 987 нче карары кабул ителде.

Конкурсның максатлары түбәндәгеләр булды:

Татарстан Республикасында иҗтимагый үзидарәләр эшчәнлеген активлаштыру һәм аларга ярдәм күрсәтү;

халыкны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җәлеп итү;

иҗтимагый үзидарәләрнең социаль проектларын билгеләү, бүләкләү һәм гамәлгә ашыру.

Конкурс йомгаклары буенча конкурс комиссиясе карары нигезендә Конкурста 30 җиңүче, 41 лауреат, кимендә 45 дипломант билгеләнде.

Грант фондының гомуми күләме 4 млн.сум тәшкил итте.

2015 елдан башлап, республика бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законнары нигезендә, иҗтимагый үзидарәләр җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә территориаль иҗтимагый үзидарәләргә ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасының муниципаль районнарына (шәһәр округларына) субсидияләр бирү күздә тотылды. 2015 елда субсидияләрнең гомуми күләме – 67,3 млн.сум, 2016 елда 69,3 млн.сум тәшкил итте.

2015 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 ел, 1 июнь, 391 нче карары нигезендә иҗтимагый үзидарәләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, республиканың муниципаль берәмлекләре территориясендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдә халыкның эшлекле һәм социаль активлыгын үстерүгә һәм стимуллаштыруга юнәлдерелгән «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы (алга таба – Республика конкурсы) гамәлгә куелды.

Республика конкурсының еллык грант фонды 50,0 млн.сум тәшкил итә.

2015 – 2016 еллардагы республика конкурсларында грант акчасын 240 җиңүче һәм призер алды.

Грантлар территорияләрне, паркларны, скверларны төзекләндерүгә, кече архитектура формаларын урнаштыруга, социаль-мәдәни чаралар үткәрүгә, бәйрәм декорацияләре, бүләкләр сатып алуга һәм куркынычсызлыкны арттыруга йөз тоткан чараларга (видеокүзәтү системаларын сатып алу һәм кую) юнәлдерелгән.

ТИҮ органнары һәм Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары гамәлләрен яраштыру, Татарстан Республикасы территориясендә ТИҮ системаларын үстерү шартларын тәэмин итү, халыкның социаль әһәмияттәге иҗтимагый инициативаларына булышлык күрсәтү һәм үстерү максатларында, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе президиумының 2016 елның 8 июнендәге ПР-17-1 нче карары белән Иҗтимагый үзидарәләрнең координация советы төзелде, һәм аның составына территорияләрендә ТИҮ төзелгән һәм эшләп килә торган Татарстан Республикасының һәр муниципаль районыннан һәм шәһәр округындагы һәр районнан бер ТИҮ җитәкчесе (рәисе) керә.»;

1 нче ярдәмче программага теркәлгән 1 нче кушымтаның «Территорияне планлаштыру проектларын әзерләү» һәм «Территорияләрне межалау проектларын әзерләү» юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Территорияне планлаштыру проектларын әзерләү | ТР ТАһТК ХМ | 2014 – 2020 еллар | территорияләрне планлаштыру проектлары саны, данә | 31 | 8 | 2 | 1 | - | - | - | - | 20500,0 ТРБ | 7500, 0 ТРБ | 7500,0 ТРБ»; | - | - | - | - |
| Территорияләрне межалау проектларын әзерләү | ТР ТАһТК ХМ | 2014 – 2020 еллар | территорияләрне межалау проектлары саны, данә | 10 | - | - | 1 | - | - | - | - | - | - | | - | - | - | - |

«2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасының (алга таба – 2 нче ярдәмче программа) паспортын, I – III бүлекләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программа исеме | «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы |
| Ярдәмче программаны төп эшләүче | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы |
| Ярдәмче программаның максаты | Инновацион икътисад формалашуның мөһим бер кисәге буларак кече һәм урта эшмәкәрлекнең нәтиҗәле эшләве һәм үсеше өчен шартлар тудыру, шулай ук Татарстан Республикасының социаль-икътисади үсеше мәсьәләләрен хәл итүдә аның кертемен арттыру |
| Ярдәмче | 1. Сәнәгатьтә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының |

<table>
<tr><td>программаның бурычлары</td><td>производстволарын яңадан технологик җиһазландыруга һәм хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә булышлык күрсәтү, шулай ук авыл җирлегендә хуҗалык итүнең кече формаларының тотрыклы үсеше өчен шартлар тудыру;<br>2. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен финанс ресурсларыннан файдалана алу мөмкинлеген арттыру;<br>3. Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү инфраструктурасының яңа формаларын төзү һәм гамәлдәгесен үстерү;<br>4. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатын күтәрү, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын фәнни-методик, норматив-хокукый һәм консультация ярдәме белән тәэмин итү;<br>5. Икътисадый актив халыкны эшмәкәрлек эшчәнлегенә җәлеп итү;<br>6. Тышкы икътисадый элемтәләрне үстерү, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары җитештерә торган продукцияне төбәк һәм чит ил базарларына чыгару өчен шартлар тудыру</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары</td><td>2014 – 2017 еллар</td></tr>
<tr><td>Еллар һәм җәлеп итәргә планлаштырыла торган чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре</td><td>Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 5 930 049,01292 мең сум<*> тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 2 225 333,79562 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 3 704 715,21730 мең сум<****>:
<table>
<tr><td rowspan="3">Ел</td><td colspan="3">Акча күләме, мең сум</td></tr>
<tr><td rowspan="2">барлыгы</td><td colspan="2">шул исәптән</td></tr>
<tr><td>Татарстан Республикасы бюджетыннан</td><td>федераль бюджеттан җәлеп итәргә планлаштырыла торган</td></tr>
<tr><td>2014</td><td>2 401 459,36820<**></td><td>707 524,79562</td><td>1 693 934,57258<**></td></tr>
<tr><td>2015</td><td>1 926 224,83009<***></td><td>511 625,9</td><td>1 414 598,93009<***></td></tr>
<tr><td>2016</td><td>1 102 364,81463<****></td><td>506 183,1</td><td>596 181,71463<****></td></tr>
</table>
</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td rowspan="3"></td><td>2017</td><td>500 000,00000 <*></td><td>500 000,0</td><td><*></td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>5 930 049,01292<****></td><td>2 225 333,79562</td><td>3 704 715,21730<****></td></tr>
<tr><td colspan="4">Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.<br><br><*> Федераль бюджет акчасы исәбеннән Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү күләме бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларын конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча ел саен билгеләнә.<br><**> Шул исәптән 193 209,83529 мең сум – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 декабрь, 1151 нче карары белән расланган 2011 – 2013 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча республика программасы чараларын тормышка ашыруга 2012 – 2013 елларда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган һәм 2014 елда үзләштерелгән акчасы.<br><***> Шул исәптән 437 206,63906 мең сум – «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыруга 2014 елда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган һәм 2015 елда үзләштерелгән акчасы.<br><****> Шул исәптән 1 364,34855 мең сум – «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыруга 2015 елда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган һәм 2016 елда үзләштерергә планлаштырыла торган акчасы</td></tr>
<tr><td>Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Ярдәмче программаның</td><td colspan="4">Ярдәмче программаны тулы күләмдә тормышка ашыру 2017 ел ахырына түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>эш белән тәэмин ителгән халыкның гомуми санында микропредприятиеләрдә, кече һәм урта предприятиеләрдә һәм шәхси эшмәкәрләрдә эш белән тәэмин ителгән хезмәткәрләрнең уртача исемлек (тышкы ике урында эшләүдән тыш) саны өлешен 25 процентка кадәр;<br>кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары санын (шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп) 1 мең кешегә исәпләгәндә 35 берәмлеккә кадәр</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |

## I. Ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсе тасвирламасы, проблемалар һәм аларны хәл итү юллары

2015 елда Татарстан Республикасында 49 мең икътисадый актив кече предприятие (2014 елга караганда 159 берәмлеккә күбрәк) һәм 488 урта предприятие (2014 елга караганда 51 берәмлеккә күбрәк), шулай ук республиканың салым органнарында теркәлгән яки яңадан теркәлү узган 87,9 мең шәхси эшмәкәр (2014 елга караганда 633 кешегә азрак) үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашырган.

Кече һәм урта эшмәкәрлек (алга таба – КУЭ) субъектлары буенча исемлек составындагы хезмәткәрләрнең уртача саны 2015 елда 2014 ел белән чагыштырганда 7,8 мең кешегә кимегән һәм 379,1 мең кеше тәшкил иткән.

Кече һәм урта предприятиеләр әйләнешендә 2013 елдан 2015 елга кадәр тотрыклы үсеш тенденциясе булган: 2015 елда әлеге күрсәткечнең мәгънәсе 930,9 млрд.сум тәшкил иткән, һәм бу 2014 ел дәрәҗәсеннән 1,8 процентка күбрәк һәм 2013 ел дәрәҗәсеннән 3,4 процентка күбрәк (кече предприятиеләр әйләнеше – 763,1 млрд.сум (2013 ел дәрәҗәсенә карата +10,8 процент), урта предприятиеләр әйләнеше – 167,8 млрд.сум (2013 ел дәрәҗәсенә карата – 13,2 процент)).

Шунысы мөһим, әлеге үсеш сан ягыннан гына түгел, сыйфат ягыннан да. 2015 елда кече һәм урта предприятиеләрнең җитештерүчәнлеге бер эш белән тәэмин ителгән кешегә 2,5 млн.сум тәшкил итте, һәм бу 2014 елга караганда 0,09 млн.сумга күбрәк.

КУЭ өлеше Татарстан Республикасының тулаем төбәк продуктында (алга таба – ТТП) 2015 елда 25,1 процент дәрәҗәсендә бәяләнә.

1 таблица

Татарстан Республикасында эшмәкәрлек өлкәсе үсешенең төп тенденцияләре

| Күрсәткеч | 2013 ел (факт) | 2014 ел (факт) | 2015 ел (бәяләү) | 2016 ел (бәяләү) |
|---|---|---|---|---|
| Икътисадый актив эшмәкәрлек субъектлары саны, шул исәптән: | | | | |
| кече предприятиеләр, мең берәмлек | 49,6 | 48,8 | 49,0 | 49,2 |
| урта предприятиеләр, берәмлек | 442 | 437 | 488 | 490 |
| республиканың салым органнарында теркәлгән | 90,6 | 88,5 | 87,9 | 88,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| яки яңадан теркәлү узган шәхси эшмәкәрләр, мең берәмлек | | | | |
| Тулаем төбәк продуктында КУЭ өлеше, процент | 25,6 | 25,5 | 25,2 | 25,0 |
| КУЭ субъектлары буенча исемлек составындагы хезмәткәрләр саны, мең кеше | 390,1 | 386,9 | 379,1 | 371,5 |
| Республикада эш белән тәэмин ителгәннәрнең гомуми санында КУЭ тармагында мәшгуль булганнар өлеше, процент | 26,4 | 26,2 | 25,8 | 25,4 |
| Кече һәм урта предприятиеләр һәм шәхси эшмәкәрләр әйләнеше, млрд.сум | 1246,3 | 1250,9 | 1265,0 | 1285,0 |

Төп күрсәткечләр анализы Татарстан Республикасында КУЭ өлкәсенең уңай үсеш динамикасы турында сөйли, һәм моңа, һичшексез, Ярдәмче программа кысаларында КУЭ субъектларына булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру ярдәм итә.

2014 елдан 2015 елга кадәр Ярдәмче программаны тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасында эшмәкәрлекне үстерүгә 4,3 млрд.сумнан артык акча, шул исәптән 1,2 млрд.сум – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм 3,1 млрд.сумнан артык – федераль бюджеттан субсидияләр исәбеннән бирелде.

Акчаның якынча 40 проценты, яки 1,7 млрд.сум, КУЭ субъектларына бизнес-проектларын тормышка ашыру өчен туры финанс ярдәме күрсәтүгә бирелде. Түбәндәге чаралар уңышлы төстә гамәлгә ашырылды:

җиһазлар лизингын үстерү: КУЭ субъектлары чыгымнарына субсидия бирү («Лизинг-грант») (689 КУЭ субъекты субсидия алды, хупланган бизнес-проектларны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2064 яңа эш урыны булдырылды);

микрозаемнар бирү механизмнарын үстерү (260 КУЭ субъекты субсидия алды, хупланган бизнес-проектларны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 159 яңа эш урыны булдырылды);

җиһазлар сатып алу чыгымнарына субсидия бирү (144 КУЭ субъекты субсидия алды, хупланган бизнес-проектларны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 442 яңа эш урыны булдырылды).

Гомуми финанслау күләменең 60 процентыннан артыгы, яки 2,8 млрд.сум, Татарстан Республикасында КУЭкә инфраструктура ярдәме күрсәтүгә бирелде.

Махсус икътисадый зоналарны, индустриаль паркларны, технопаркларны, муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыкларын үстерү дәвам иттерелә. Яңа эш урыннары булдырыла, яңа резидентлар җәлеп ителә, резидент-компанияләрнең Татарстан Республикасының эре предприятиеләре белән тыгыз кооперациясе гамәлгә ашырыла.

Бүгенге көндә резидент-предприятияләрдә мәшгуль булганнар саны 31 меңнән артык кеше тәшкил итә, 2015 ел йомгаклары буенча резидентлар тарафыннан 120,0 млрд.тан артык сумга продукция җитештерелгән, һәм бу

республикада сәнәгать җитештерүенең бөтен күләменнән 7 процентка якын тәшкил итә.

2007 елдан алып, Татарстан Республикасы бюджеты акчасыннан тыш, сәнәгать парклары төзүгә Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы линиясе буенча федераль бюджет акчасы җәлеп ителә башлады (Россиядә беренче агросәнәгать паркы төзелде).

Татарстан беренчеләрдән булып хосусый парклар буенча дәүләт ярдәме алды, аларны финанслау программасы 2013 елда башланды.

Киләсе адым федераль дәрәҗәдәге эре сәнәгать паркларына гына түгел, аларны төзү кечерәк территорияләрне үстерергә ярдәм иткән муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыкларына да ярдәм күрсәтү мөмкинлеге турында Татарстан Республикасы инициативасы булды. 2014 – 2016 елларда сәнәгать парклары инфраструктурасын төзүгә федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасыннан 1,5 млрд.сумнан артык бирелде.

Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыклары төзү муниципалитетларның эшлекле активлыгын арттыру, эш урыннары булдыру, шәһәрләр һәм районнарның керемнәре базасын арттыруның нәтиҗәле ысулы булып тора.

Гамәлдәге муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйланчыкларында 292 резидент эшчәнлеген гамәлгә ашыра, 5,7 меңнән артык эш урыны булдырылган. 2015 ел йомгаклары буенча җитештерелгән продукциянең фаразланган күләме 13,2 млрд.сумнан артык тәшкил итте.

2014 елда «Кама кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын кластерлы үстерү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы (алга таба – Кама КҮҮ) төзелде. Кама КҮҮ максаты булып республиканың кластер инициативаларын тормышка ашырганда эшмәкәрлек субъектларының, фәнни һәм белем бирү, коммерциячел булмаган һәм иҗтимагый оешмаларның, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының нәтиҗәле хезмәттәшлеге өчен шартлар тәэмин итү тора.

Кама КҮҮ тарафыннан 2 тармак кластеры төзелде:

машина төзелеше кластеры;

ИТ-кластер.

2015 ел йомгаклары буенча Кама КҮҮ чараларын тормышка ашырганда 150 КУЭ субъектына ярдәм күрсәтелде.

Яшьләрнең югары технологияле фән һәм техника тармаклары белән кызыксынуын стимуллаштыру, талантларны ачыклау һәм Татарстан Республикасының булачак инженер-техник элитасын формалаштыру максатларында, 2012 елдан «Яшьләр инновацион сәнгате үзәкләрен төзү һәм үстерү» чарасы тормышка ашырыла. Проект кысаларында федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 81,0 млн.сум гомуми суммада Татарстан Республикасы территориясендә челтәр төзелде, ул республиканың эре шәһәрләрендә һәм районнарында урнашкан 17 яшьләр инновацион сәнгате үзәгеннән тора.

Инфраструктураны үстерүдә яңа юнәлешләрнең берсе 2013 – 2014 елларда түбәндәге төбәк инжиниринг үзәкләрен һәм прототиплаштыру үзәкләрен төзү булды:

«КАИ-ЛАЗЕР» сәнәгать лазерь технологияләре төбәк инжиниринг үзәге, КУЭ предприятиеләренең технология җитештерү комплексларында заманча лазерь технологияләре (эретеп ябыштыру, кисү, келәймә сугу, ныгыту, металл йөгертү, фрезер белән эшкәртү) гамәлгә кертү өчен төзелгән;

«Медицина фәне үзәге» медицина симуляторлары төбәк инжиниринг үзәге, аның төп эшчәнлек максаты булып медицина өлкәсендә җитештерүчеләрнең һәм медицина дәвалау учреждениеләренең, шул исәптән КУЭ технологик әзерлеген арттыру сәбәпле югары технологияле медицина хезмәтләре күрсәтү дәрәҗәсен күтәрү тора, медицина җиһазларын һәм инструментларны нәтиҗәле гамәлгә кертүне һәм куллануны гамәлгә ашыручы компанияләр җитештерә һәм файдалана торган махсуслаштырылган медицина виртуаль симуляторлары булдыру (проектлаштыру) исәбенә;

Химия технологияләре өлкәсендә төбәк инжиниринг үзәге (инжиниринг хезмәтләре нефть эшкәртү, нефть химиясе, химия, композицион полимер материаллар һәм машина төзелеше өлкәсендә күрсәтелә);

Татарстан Республикасының биотехнологияләр төбәк инжиниринг үзәге, аның төп эшчәнлек максаты булып технологик һәм техник процессларны эшләү (проектлаштыру) һәм КУЭ субъектларында барлыкка килә торган проект, инженерлык, технологик һәм оештыру-гамәлгә кертү бурычларын хәл итүне тәэмин итү исәбенә КУЭ субъектларының биотехнологияләр өлкәсендә технологик, оештыру, идарәчелек әзерлеген арттыру тора;

Үзебезнең ил робот техникасын прототиплаштыру һәм гамәлгә кертү үзәге, ул конструкторлык документларын һәм эшләнмәләрнең 3D-модельләрен эшләүдә, прототиплар әзерләү һәм эшләнмәләрнең вак партияләрен чыгаруда, шулай ук компьтер модельләрен ясаудан, роботлаштырылган комплексларның һәм җиһазларның компонентларын һәм прототипларын ясаудан алып алга таба кече һәм урта предприятиеләрдә технологик җиһазландыруга (гамәлгә кертү) кадәр тулы җитештерү системасын эшләүдә специальләшә торган инженерлык-сәнәгать мәйданчыгы булып тора;

Санлы технологияләр үзәге, аның төп эшчәнлек максаты булып, эшкәртүне югары төгәллектә башкаруга ярдәм итә торган иң яңа технологияләр һәм җиһазлар кулланып, югары төгәллектәге җитештерү һәм катлаулы эшләнмәләр сертификатлаштыру буенча тулы хезмәтләр комплексын күрсәтү, әйберләрне эшләү, җитештерү һәм эшләп бетерүнең ресурслар сыйдырышлыгын киметү тора.

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне нәтиҗәле үстерүгә булышлык күрсәтү максатларында, 2013 елда Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү үзәге төзелде. Аның төп эшчәнлек максаты булып Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен уңай шартлар тудыруны тәэмин итү, КУЭ субъектлары санын һәм алар җитештерә торган товарлар (башкара торган эшләр, күрсәтә торган хезмәтләр) өлешен ТТП күләмендә арттыруга булышлык күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итүдә катнашу һәм үзмәшгульлекне үстерү, КУЭ субъектлары эшчәнлеген мәгълүмат-консультация ягыннан тәэмин итү, семинарлар, конференцияләр, форумнар, «түгәрәк өстәлләр» һ.б. үткәрү тора.

Татарстан Республикасының кече һәм урта предприятиеләре-экспортерларының тышкы икътисадый эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү максатларында, 2012 елда Татарстан Республикасында экспортка юнәлдерелгән КУЭ субъектларына ярдәм күрсәтүне яраштыру үзәге төзелде. Аның төп эшчәнлек максаты булып Татарстан Республикасының экспортка юнәлдерелгән кече һәм урта предприятиеләрен чит ил базарларына чыгаруда булышлык күрсәтү тора.

Татарстан Республикасының социаль эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм үстерү максатларында, 2015 елда Татарстан Республикасының социаль өлкәдә инновацияләр үзәге төзелде, һәм ул социаль эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтүнең гамәлдәге төрләрен камилләштерүгә юнәлдерелгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә социаль проблемаларны хәл итүгә, республика дәрәҗәсендә социаль хезмәтләр сыйфатын күтәрүдә булышлык күрсәтүгә, социаль өлкәдә эшли торган оешмаларның нәтиҗәлелеген арттыруга йөз тоткан нәтиҗәле чаралар системасын төзүгә юнәлдерелгән.

КУЭ субъектларының һәм Татарстан Республикасында эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү инфраструктурасы оешмаларының кредиттан һәм башка финанс ресурсларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү максаты белән «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциячел булмаган оешмасы һәм «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясе төзелде.

Татарстан Республикасы Гарантия фондының бурычы – КУЭ субъектларының һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү инфраструктурасын тәшкил иткән оешмаларның бурычлары буенча (кредитлар, заемнар, лизинг шартнамәләре) поручительлек бирү.

Татарстан Республикасы Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фондының бурычы – КУЭ субъектлары һәм инфраструктура оешмалары нигезләгән теләсә нинди максатларга микрозаемнар бирү, вакыты чыккан салым түләүләрен, вакыты чыккан кредиторлык бурычларын, хезмәткәрләргә эш хакы түләү буенча вакыты чыккан бурычларны каплаудан, керемнәрне түләү буенча катнашучыларга (гамәлгә куючыларга) бурычларны түләүдән, катнашучыларның (гамәлгә куючыларның) устав капиталындагы өлешен сатып алудан тыш.

## II. Ярдәмче программаның максаты, бурычлары, төп чаралары тасвирламасы, аны гамәлгә ашыру вакытлары һәм этаплары

Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм үстерү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте эшмәкәрлек субъектларының эшлекле активлыгы үсеше өчен уңай климат тудыруга, эшмәкәрлекне үстерүнең төп чикләүләре йогынтысын киметүгә юнәлдерелгән һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү юнәлешләрен Татарстан Республикасын үстерүнең стратегик максатлары, бурычлары һәм өстенлекләре системасына кертүгә нигезләнгән.

Әлеге максат белән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының төп стратегик документларына даими анализ үткәрелә, урта вакытлы перспективага социаль-икътисадый үсешнең төп бурычлары билгеләнә, һәм әлеге бурычлар кысаларында КУЭ субъектларына ярдәм күрсәтү чараларын тормышка ашыру тәкъдим ителә.

«Опора России», «Деловая Россия» гомумроссия иҗтимагый оешмалары, шулай ук Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты тарафыннан үткәрелә торган һәм эшмәкәрләр берләшмәсен сораштырулар һәм анкеталар мәгълүматларына нигезләнә торган эшмәкәрлек үсеше проблемалары буенча тикшеренүләр нигезендә Россия Федерациясе субъектларында, шул исәптән Татарстан Республикасында, эшмәкәрлек үсешен тоткарлый торган төп проблемалар булып түбәндәгеләр тора:

кадрлар дефициты;

салым йөкләнешенең кече һәм урта бизнес өчен югары дәрәҗәсе;

финанс ресурсларыннан файдалана алу мөмкинлегенең түбән дәрәҗәсе;

җир һәм күчемсез мөлкәттән файдалана алу мөмкинлегенең түбән дәрәҗәсе;

энергетика инфраструктурасыннан файдалана алу мөмкинлегенең түбән дәрәҗәсе;

административ каршылыклар булу;

коррупция;

яңа җиһазлар сатып алуда проблемалар.

Ярдәмче программаның максаты булып инновацион икътисад формалашуның мөһим бер кисәге буларак кече һәм урта эшмәкәрлекнең нәтиҗәле эшләве һәм үсеше өчен шартлар тудыру, шулай ук Татарстан Республикасының социаль-икътисади үсеше мәсьәләләрен хәл итүдә аның кертемен арттыру тора.

Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

КУЭ субъектлары өчен финанс ресурсларыннан файдалана алу мөмкинлеген арттыру;

КУЭ субъектларына дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатын күтәрү, КУЭ субъектларын фәнни-методик, норматив-хокукый һәм консультация ярдәме белән тәэмин итү;

икътисадый актив халыкны эшмәкәрлек эшчәнлегенә җәлеп итү;

тышкы икътисадый элемтәләрне, КУЭ субъектлары җитештерә торган продукцияне төбәк һәм чит ил базарларына чыгару өчен шартлар тудыру.

Ярдәмче программаның төп чаралары Ярдәмче программаның максатыннан һәм бурычларыннан чыгып формалаштырылды. Шул ук вакытта һәр бурычны хәл итү кысаларында эшмәкәрлеккә, шул исәптән эшли башлаган КУЭ субъектларына, аларның санын арттыру өлешендә дә, бизнесын үстерү өлешендә дә ярдәм күрсәтүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән чаралар каралган, һәм бу яңа эш урыннарын булдыруны күздә тота.

2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында КУЭ субъектларына ярдәм күрсәтү чараларын эшләгәндә төп проблемаларны билгели торган эшмәкәрләрне бәйсез сораштырулар мәгълүматлары исәпкә алынды.

Ярдәмче программаның төп чаралары тасвирламасы

КУЭ субъектларына ярдәм күрсәтү чараларын, тулаем алганда, 3 төп юнәлешкә бүләргә була:

а) КУЭ субъектларына финанс ярдәме күрсәтү чаралары;

б) республикада эшмәкәрлекне үстерү инфраструктурасын төзүгә юнәлдерелгән чаралар;

в) эшмәкәрлекне үстерү буенча башка чаралар.

Эшмәкәрләр өчен финанс ярдәме күрсәтү юнәлеше кысаларында түбәндәге чаралар күздә тотыла:

җиһазлар лизингын үстерү: КУЭ субъектлары чыгымнарына субсидия бирү («Лизинг-грант»);

КУЭ үстерү буенча муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны) тормышка ашыру кысаларында, шул исәптән монопрофильле муниципаль берәмлекләрнең, КУЭ субъектларына ярдәм күрсәтү;

микрозаемнар бирү механизмнарын үстерү;

КУЭ субъектларына ярдәм күрсәтүнең гарантияле механизмнарын үстерү;

бизнес-инкубацияләү процессларын үстерү һәм бизнес-инкубаторларның агымдагы эшчәнлеген тәэмин итү;

яшьләр инновацион сәнгате үзәкләрен төзү һәм үстерү;

«Теләче» сәнәгать паркын үстерү (I чират төзелеше, 10 га);

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Агач эшкәртү» хосусый сәнәгать паркын үстерү;

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының полимерлар эшкәртү буенча муниципаль дәрәҗәдәге 2 нче сәнәгать мәйданчыгын төзү;

Чаллы шәһәренең «Развитие» сәнәгать паркын төзү;

«Сокуры» сәнәгать паркының 2 нче чират төзелеше;

«КЗСК» ААҖ мәйданында сәнәгать паркының энергетика һәм транспорт инфраструктурасын төзү һәм үстерү (1 этап);

«Химград» технополисы территориясендә Индустриаль паркны үстерү;

«Мастер» Кама индустриаль паркын үстерү;

«Химград» технополисы инфраструктурасын үстерү (Казан шәһәре, Восстание ур., 100 нче йорт);

ТР Мамадыш муниципаль районында «Вятка» сәнәгать паркының 1 нче чират төзелеше;

«Кукмара» сәнәгать паркының 1 нче чират төзелеше;

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авылында сәнәгать мәйданчыгын комплекслы уңайлаштыру;

«Актаныш» сәнәгать паркын төзү;

җиһазлар сатып алу чыгымнарына субсидия бирү;

Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарга субсидия бирү;

Кама КУЭ субъектларын кластерлы үстерү үзәген үстерү;

Санлы технологияләр үзәген үстерү;

Үзебезнең ил робот техникасын прототиплаштыру һәм гамәлгә кертү үзәген үстерү;

Татарстан Республикасының биотехнологияләр төбәк инжиниринг үзәген үстерү;

«КАИ-ЛАЗЕР» сәнәгать лазерь технологияләре төбәк инжиниринг үзәген үстерү;

Химия технологияләре өлкәсендә төбәк инжиниринг үзәген үстерү;

«Медицина Фәне Үзәге» медицина симуляторлары төбәк инжиниринг үзәген үстерү;

Социаль өлкәдә инновацияләр үзәге эшчәнлеген тәэмин итү;

КУЭ үстерү проблемалары һәм аларны хәл итү юллары буенча социология һәм маркетинг тикшеренүләре үткәрү (территориаль яктылыкта, икътисадый эшчәнлек төрләре буенча, ярдәмче программа чаралары яктылыгында);

Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү үзәге эшчәнлеген тәэмин итү;

«Татарстан Республикасының Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» ДКУ эшчәнлеген тәэмин итү;

кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү инфраструктурасын үстерү концепциясен эшләү;

эшмәкәрлек субъектларына дәүләт, муниципаль, өстәмә (иярчен) хезмәтләр күрсәтүгә юнәлдерелгән күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру буенча пилот проекты үткәрү (бизнес үзәкләре);

яшьләр эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү:

яшьләрне эшмәкәрлек эшчәнлегенә җәлеп итүгә юнәлдерелгән мәгълүмати кампания үткәрү;

14 – 17 яшьтәге югары сыйныф укучылары арасында уен һәм тренинг чаралары, белем бирү курслары, конкурслар уздыру;

бизнес алып бару һәм кече һәм урта предприятиеләр төзү күнекмәләрен алуга юнәлдерелгән мәгариф программалары буенча уку узу максатында эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнү сәләте булган 30 яшькәчә (30 яшьтәгеләрне дә кертеп) физик затларны сайлап алу;

30 яшькәчә физик затларны бизнес алып бару һәм кече һәм урта предприятиеләр төзү күнекмәләрен алуга юнәлдерелгән мәгариф программалары буенча укытуны оештыру;

«Россиянең яшь эшмәкәре» бөтенроссия конкурсының төбәк этабын үткәрү;

бизнес-проектлар конкурслары үткәрү;

яшь эшмәкәрләргә консультация хезмәтләре күрсәтү;

яшьләр эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм үстерүгә юнәлдерелгән төбәкара, гомумроссия һәм халыкара чараларда катнашуны тәэмин итү;

яшьләрне эшмәкәрлек эшчәнлегенә җәлеп итүгә юнәлдерелгән чаралар нәтиҗәлелеге мониторингын гамәлгә ашыру;

КУЭ субъектларына мәгълүмати ярдәм күрсәтү буенча кампания оештыру һәм үз бизнесыңны булдыруны популярлаштыру;

Татарстан Республикасында хакимият һәм бизнес хезмәттәшлеге системасын оештыру;

«Татарстан Республикасында КУЭ субъектларына ярдәм күрсәтү» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасын төзү һәм ярдәм күрсәтү чаралары нәтиҗәлелеге мониторингы;

Татарстан Республикасында экспортка юнәлдерелгән КУЭ субъектларына ярдәм күрсәтүне яраштыру үзәге эшчәнлеген тәэмин итү.

Максатлар һәм бурычлар яктылыгында төп чаралар исемлеге әлеге Ярдәмче программага теркәлгән кушымтада китерелде.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакыты: 2014 – 2017 еллар.

## III. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 5 930 049,01292 мең сум<*> тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 2 225 333,79562 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 3 704 715,21730 мең сум<****>:

| Ел | Акча күләме, мең сум | | |
|---|---|---|---|
| | барлыгы | шул исәптән | |
| | | Татарстан Республикасы бюджетыннан | федераль бюджетан җәлеп итәргә планлаштырыла торган |
| 2014 | 2 401 459,36820<**> | 707 524,79562 | 1 693 934,57258<**> |
| 2015 | 1 926 224,83009<***> | 511 625,90000 | 1 414 598,93009<***> |
| 2016 | 1 102 364,81463<****> | 506 183,10000 | 596 181,71463<****> |
| 2017 | 500 000,00000 <*> | 500 000,00000 | <*> |
| Барысы | 5 930 049,01292<****> | 2 225 333,79562 | 3 704 715,21730<****> |

Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

<*> Федераль бюджет акчасы исәбеннән Программаны ресурслар белән тәэмин итү күләме бюджетларына федераль бюджеттан кече һәм урта эшмәкәрлеккә дәүләт ярдәме күрсәтүгә субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларын конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча ел саен билгеләнә.

<**> Шул исәптән 193 209,83529 мең сум – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 декабрь, 1151 нче карары белән расланган 2011 – 2013 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча республика программасы чараларын тормышка ашыруга 2012 – 2013 елларда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган һәм 2014 елда үзләштерелгән акчасы.

<***> Шул исәптән 437 206,63906 мең сум – «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыруга 2014 елда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган һәм 2015 елда үзләштерелгән акчасы.

<****> Шул исәптән 1 364,34855 мең сум – «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы

чараларын тормышка ашыруга 2015 елда алынган федераль субсидияләрнең үзләштерелми калган һәм 2016 елда үзләштерергә планлаштырыла торган акчасы.»;

2 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

«2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү» ярдәмче программасын яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

«2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 3 нче ярдәмче программа):

3 нче ярдәмче программа паспортының «Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td>
<td>
Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 545 346,25 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 69 423,89 мең сум, федераль бюджет акчасы – 429 882,19 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан – 46 040,17 мең сум:
<table>
<tr><th rowspan="3">Ел</th><th colspan="4">Акча күләме, мең сум</th></tr>
<tr><th rowspan="2">барлыгы</th><th colspan="3">шул исәптән</th></tr>
<tr><th>федераль бюджеттан <*></th><th>Татарстан Республикасы бюджетыннан <*></th><th>бюджеттан тыш чыганаклардан <*></th></tr>
<tr><td>2015</td><td>212 812,25</td><td>158 632,69</td><td>18 339,39</td><td>35 840,17</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>10 200,00</td><td>0</td><td>0</td><td>10 200,00</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>161 292,00</td><td>135 743,50</td><td>25 548,50</td><td>0</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>161 042,00</td><td>135 506,00</td><td>25 536,00</td><td>0</td></tr>
<tr><td>Барысы</td><td>545 346,25</td><td>429 882,19</td><td>69 423,89</td><td>46 040,17</td></tr>
</table>
Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль программалары һәм башка юнәлешләр кысаларында Кластерны үстерү буенча чараларны финанслау күләме 8 386 743,52 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 5 204 225,59 мең сум, федераль бюджет акчасы – 1 597 609,74 мең сум, муниципаль берәмлекләр бюджетлары акчасы – 1 584 908,19 мең сум:
</td>
</tr>
</table>

| | Ел | Акча күләме, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | шул исәптән | | |
| | | | федераль бюджеттан <*> | Татарстан Республикасы бюджетыннан <*> | бюджеттан тыш чыганаклардан <*> |
| | 2015 | 6 804 330,82 | 1 597 609,74 | 4 402 972,89 | 803 748,19 |
| | 2016 | 1 162 926,22 | 0 | 683 513,22 | 479 413,00 |
| | 2017 | 419 486,48 | 0 | 117 739,48 | 301 747,00 |
| | 2018 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | Барысы | 8 386 743,52 | 1 597 609,74 | 5 204 225,59 | 1 584 908,19 |
| | <*> Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен һәм инновацион территориаль кластерларны үстерүгә комплексы инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен субсидияләр бүлеп бирү буенча Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы конкурсы йомгакларын исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»; | | | | |

3 нче ярдәмче программаның I бүлегендәге «Кластерда катнашучылар (Ярдәмче программада катнашучылар)» бүлекчәсенең 3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Килешү буенча катнашучы Кластер предприятиеләре:

«Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ, «Татнефть» ГАҖ нефть химиясе комплексы, «КАМАЗ» ГАҖ, «ТАНЕКО» АҖ, «Аммоний» АҖ, «ТАИФ-НК» ААҖ, «Л.Я.Карпов исемендәге химия заводы» АҖ, «Ростар» фәнни-җитештерү берләшмәсе» ҖЧҖ, «Кама Кристалл Технолоджи» ҖЧҖ, «Татнефть-Нефть химиясе» идарә итүче компаниясе» ҖЧҖ, «Татнефтехиминвест-холдинг» ААҖ, «Технологияләр Трансферы Үзәге» ҖЧҖ, «Магнолия» Чаллы металл коюмеханика заводы» ҖЧҖ, «Автоагрегат үзәге» Кама заводы» ЯАҖ, «Кориб» ҖЧҖ, «Татпроф» ЯАҖ, «Начало» җитештерү берләшмәсе» ҖЧҖ, «Яңа металл кою технологияләре» ҖЧҖ, «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» АҖ резидентлары («Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» ҖЧҖ идарә итүче компаниясе, «Джошкуноз-Алабуга» ҖЧҖ, «Алабуга-Моторс» ҖЧҖ, «Мир Упаковки» ЯАҖ, «Хаят Кимья» ҖЧҖ, «Аутоматив Гласс Альянс Рус» ЯАҖ, «П-Д Татнефть-Алабуга Стекловолокно» ҖЧҖ, «Тракья Гласс Рус» ЯАҖ, «Армстронг Билдинг Продактс» ҖЧҖ, «Хухтамаки Фудсервис Алабуга» ҖЧҖ, «Алабуга-Волокно» ҖЧҖ, «НЦК-Алабуга» ҖЧҖ, «Форд Соллерс Алабуга» ҖЧҖ, «Интерскол-Алабуга» АҖ, «Амитек» ҖЧҖ, «Дизайн-Рус» ҖЧҖ, «Татпластик» ҖЧҖ, «3М Волга» ҖЧҖ), «Эйдос-Медицина» ҖЧҖ, «Интеллос» ҖЧҖ, «КАМАТЕК» ҖЧҖ, «Татнефть-Пресскомпозит» ҖЧҖ, «Связьинвестнефтехим» ААҖ, «КамЭнергоРемонт» ҖЧҖ, «Эйдос-Роботехника»

ҖЧҖ, «Транссервис-ЛТД» ҖЧҖ, «РИАТ» ААҖ, «Мефро уилз Руссиа Завод Заинск» ҖЧҖ, «Форд Соллерс Холдинг» ҖЧҖ, «РЕМДИЗЕЛЬ» ҖЧҖ, «Алабуга автомобиль заводы» җитештерү берләшмәсе» ҖЧҖ, «Астейс» ЯАҖ, «ЦФ КАМА» ҖЧҖ, «КАММИНЗ КАМА» ЯАҖ, «Кнорр-Бремзе КАМА» ҖЧҖ, «Чаллы шәһәренең инвестицияләр җәлеп итү агентлыгы» ААҖ, «Комплексное ЭнергоРазвитие – Инжиниринг» ҖЧҖ, « Идарә системалары һәм интеграцияләнгән мәгълүмат технологияләре лабораториясе» ҖЧҖ, «Штурман КРЕДО+» автосәнәгать холдингы» ҖЧҖ, «ТехноТрейд» ҖЧҖ, «Татарстан Республикасының җитештерү субконтрактациясе үзәге» дәүләт коммерциячел булмаган фонды, «Татпроф» алюминий продуктлары» ҖЧҖ, «Риэль Инжиниринг» ҖЧҖ, «СПРУТ-Технология» ҖЧҖ, «ДубльГис – Чаллы» ҖЧҖ, «ТТК Волга» ҖЧҖ, «Полиматиз» ЯАҖ, «Татэлектромаш» ААҖ, «Химтраст» ЯАҖ, «БАКЕЛИТ» полимер материаллар заводы» ҖЧҖ, «С.П.Титов исемендәге Чаллы катыргы-кәгазь комбинаты халык предприятиесе» ЯАҖ, «Хитон-пласт» компанияләре төркеме, «Автотехник» ҖЧҖ, «Махсус трансмиссияләр» ҖЧҖ, «Машдеталь заводы» ҖЧҖ, «НПФ Универсал Кардан Деталь» ҖЧҖ, «КОРА» ҖЧҖ, «ТИССАН» ҖЧҖ, «Автодизайн» проект-җитештерү фирмасы» ҖЧҖ, «РАБИКА-ЭНЕРГИЯ САКЛАУ» ҖЧҖ, «Гранд-НЧ» ҖЧҖ, «АрСиЭр» ҖЧҖ, «Дамин» ҖЧҖ, ИП Осенков, «Вектор» ҖЧҖ, «ПКФ «Автокомпоненты-Трейд» ҖЧҖ, «Профтермо заводы» ҖЧҖ, «Күтәрткеч төзелеш машиналары» ҖЧҖ, «Кама тормоз аппаратурасы һәм агрегатлар заводы» ҖЧҖ, «Яңа Технологияләр» ҖЧҖ, «Техпром+» ҖЧҖ, «Пласт-Стройкомплект» ҖЧҖ, «КАТТЕР» Чаллы Метиз Заводы» ҖЧҖ, «ДАХАН-РУС» ҖЧҖ, «СпецПромАгрегат» җитештерү-сәнәгать компаниясе» ҖЧҖ, «ПФ Автотехпласт» ҖЧҖ, «Биформ» ҖЧҖ, «Кондиционер» фәнни-җитештерү фирмасы» ҖЧҖ, «Грандис Моторс» ҖЧҖ, «Атон Импульс» ҖЧҖ, «Термокам» ҖЧҖ, «Җылылык челтәрләре» ҖЧҖ, «СтартПласт» ҖЧҖ, «Тарта торган механизмнар» ҖЧҖ, «Малое и мобильное» ҖЧҖ, «Кама Ремонт Үзәге» ҖЧҖ, «ПФ Камтехлин» ҖЧҖ, «БЛИК» ҖЧҖ, «Техно-Трейд» техник сервис үзәге» ҖЧҖ, «ОКА» сәүдә йорты» ҖЧҖ, «КАМКРАНМАШ» ҖЧҖ, «Гидромаркет» ҖЧҖ, «КРАСТ» инженерлык-җитештерү фирмасы» ҖЧҖ, «АвтоСтар» ҖЧҖ, «АВТО-ЖГУТКОМПЛЕКТ» ҖЧҖ, «КАМЭК» ЯАҖ, «Авторитм» ҖЧҖ, «Мирас» ҖЧҖ, «Алтиком Сәүдә-Сәнәгать Компаниясе» ҖЧҖ, «ОЛЕОКАМ» ҖЧҖ, «Аккор заводы» ҖЧҖ, «КАММАШ» ҖЧҖ, «Камская кузница» ҖЧҖ, «Пчелопром» авыл хуҗалыгы предприятиесе» ҖЧҖ, «РОСТ» җитештерү-коммерция фирмасы» ҖЧҖ, «Седан» ЯАҖ, «Технодеталь» җитештерү-коммерция фирмасы» ҖЧҖ, «Магнат» ҖЧҖ, «Механика» фәнни-җитештерү берләшмәсе» ҖЧҖ, «Энерготехпромсервис» ҖЧҖ; «АВТОЛИТ» ҖЧҖ, «Автостремянка.ру» ҖЧҖ, «Әлмәт машина төзү заводы» ҖЧҖ, «Лениногорск механика заводы» ҖЧҖ, «ТИС» ҖЧҖ, «Магнолия-С» ҖЧҖ, «КонтурКабель» ҖЧҖ, «Толедо» сәүдә-финанс компаниясе» ҖЧҖ, «Прайм-пласт» ҖЧҖ, «ЭКО Полимер-Сервис» ҖЧҖ, «Теплолюкс-Түбән Кама» ҖЧҖ, «ТатТехГруп» ҖЧҖ, «Эластик заводы» ҖЧҖ, «Кампласт» ҖЧҖ, «КамПласт» инновация-җитештерү компаниясе» ҖЧҖ, «АМК-Композит» ҖЧҖ, «Кама торбалары заводы» ҖЧҖ, «Агропласт» ҖЧҖ, «ИнТехПласт» ҖЧҖ, «ПолимерХимПром» ҖЧҖ, «Полимер-Хим НК» ҖЧҖ, «ПластиК» җитештерү берләшмәсе» ҖЧҖ, «Полимеркварц заводы» ҖЧҖ, «Индустриальная земля» идарә

итүче компаниясе» ҖЧҖ, «ТехноКам» ҖЧҖ, ИП Новицкий Д.В., «Кама полимер материаллар заводы» ҖЧҖ, «РЕЛИЗ» ҖЧҖ, «Тритон М» ҖЧҖ, «ТатхимПласт» ҖЧҖ, «Эритренъ» ҖЧҖ, «Сабур» ҖЧҖ, «Луч» ҖЧҖ, «ЭЛЬПАК» ҖЧҖ, «Директория» сәүдә-җитештерү компаниясе» ҖЧҖ, «Автопласт» ҖЧҖ, «Гамма-пласт» ҖЧҖ, «Политруб» ҖЧҖ, «Р-Пластик» ҖЧҖ, «СафПласт» ҖЧҖ, «Технотрон» җитештерү компаниясе» ЯАҖ, «Казан медицина инструментлары заводы» ААҖ, «Диалинг-Маркет» ҖЧҖ, «Техстрой» ҖЧҖ, «КазанГидроПласт» ҖЧҖ, «Трубопласт» җитештерү компаниясе» ҖЧҖ, «Полимер эшләнмәләр» ҖЧҖ, «ПОЛИПАК» ҖЧҖ, «Тех-Мастер» ҖЧҖ, «КамПолиБэг» сәүдә компаниясе» ҖЧҖ, «КВАРТ» АҖ, «АНСАН-Алабуга» ҖЧҖ, «Алабуга Пластик» ҖЧҖ, «Протон» ЯАҖ, «Лин Вектор» ҖЧҖ, «РариТЭК» ҖЧҖ, «Республика Компетенция һәм Инновация Интеграция Үзәге» ҖЧҖ, «Зәй нефть эшкәртү» ҖЧҖ, ҖЧҖ, «Гефест» «Термолит» төгәл металл кою заводы» ҖЧҖ, «Огниво» ҖЧҖ, «Татарстан Республикасының машина төзү кластеры» ассоциациясе, «Механик трансмиссияләр заводы» ҖЧҖ, «УК «КОМ» ҖЧҖ, «Айтирус» ҖЧҖ, «ПРЕТТЛЬ-НК» ҖЧҖ, ПКФ «Инстромет» ҖЧҖ, Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы, Чаллы шәһәре һәм «Кама аръягы» төбәге Сәүдә-сәнәгать палатасы, «Чаллы кран заводы» АҖ, «КамВент-ПРО» ҖЧҖ, «Автокомпания» ҖЧҖ, «Автомобиль техникасы компаниясе» җитештерү-коммерция фирмасы» ҖЧҖ, «Автоцветлит» ҖЧҖ, «Кастинг» җитештерү фирмасы» ҖЧҖ, «КОМБАТ» ҖЧҖ, «Чаллы машина төзү заводы» сәүдә йорты» ҖЧҖ, «Росла» ҖЧҖ, «Техпром маш» ҖЧҖ, «Чаллы Агрегат» җитештерү предприятиесе» ҖЧҖ, «КАМАЗ» тышкы сәүдә компаниясе» АҖ, «АвтоЗапчасть КАМАЗ» ҖЧҖ, «Автомастер» ҖЧҖ, «Рифек» ҖЧҖ, «Термик эшкәртү технологияләре фәнни-җитештерү үзәге» ҖЧҖ, «Маркетинг тикшеренүләре үзәге» ҖЧҖ.»;

Ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 545 346,25 мең сум <*> тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 69 423,89 мең сум <*>, федераль бюджет акчасы – 429 882,19 мең сум <*>, бюджеттан тыш чыганаклардан – 46 040,17 мең сум<*>.

| Ел | Акча күләме, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | шул исәптән | | |
| | | федераль бюджеттан <*> | Татарстан Республикасы бюджетыннан <*> | бюджеттан тыш чыганаклардан <*> |
| 2015 | 212 812,25 | 158 632,69 | 18 339,39 | 35 840,17 |
| 2016 | 10 200,00 | 0 | 0 | 10 200,00 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2017 | 161 292,00 | 135 743,50 | 25 548,50 | 0 |
| 2018 | 161 042,00 | 135 506,00 | 25 536,00 | 0 |
| Бары-сы | 545 346,25 | 429 882,19 | 69 423,89 | 46 040,17 |

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль программалары һәм башка юнәлешләр кысаларында Кластерны үстерү буенча чараларны финанслау күләме 8 386 743,52 мең сум <*> тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 5 204 225,59 мең сум <*>, федераль бюджет акчасы – 1 597 609,74 мең сум <*>, муниципаль берәмлекләр бюджетлары – 1 584 908,19 мең сум<*>.

| Ел | Акча күләме, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | шул исәптән | | |
| | | федераль бюджеттан <*> | Татарстан Республикасы бюджетыннан <*> | муниципаль берәмлекләр бюджетларыннан җәлеп итәргә планлаштырыла торган <*> |
| 2015 | 6 804 330,82 | 1 597 609,74 | 4 402 972,89 | 803 748,19 |
| 2016 | 1 162 926,22 | 0 | 683 513,22 | 479 413,00 |
| 2017 | 419 486,48 | 0 | 117 739,48 | 301 747,00 |
| 2018 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Барысы | 8 386 743,52 | 1 597 609,74 | 5 204 225,59 | 1 584 908,19 |

<*> Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен һәм инновацион территориаль кластерларны үстерү буенча комплексы инвестиция проектларын тормышка ашыруга субсидияләр бүлеп бирү буенча Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы конкурсы йомгакларын исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. Финанслау чыганакларын һәм күләмнәрен күрсәтеп, Ярдәмче программа чараларын җентекләп тасвирлау Ярдәмче программага теркәлгән 2 нче кушымтада китерелә.»;

3 нче ярдәмче программага 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков